КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 14 апрель г.Казань № 408

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга айлык өстәмә акчалата түләү бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 429 нчы, 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче, 2013 ел, 12 март, 157 нче, 2013 ел, 31 октябрь, 828 нче, 2015 ел, 29 июль, 550 нче, 2016 ел, 26 декабрь, 997 нче, 2017 ел, 13 июль, 494 нче, 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче, 2019 ел, 17 сентябрь, 839 нчы, 2020 ел, 2 июнь, 461 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче, 2021 ел, 10 апрель, 236 нчы, 2021 ел, 27 декабрь, 1303 нче, 2022 ел, 11 март, 214 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы, 2024 ел, 01 февраль, 53 нче, 2024 ел, 30 май, 376 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

беренче абзацка «Гаиләнең җан башына һәм ялгыз яшәүче гражданның аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге турында (алга таба - Исемлек)»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен акчалата түләү билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар белән айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза биргәннән соң бер ай алдан булган соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә (алга таба - хисап чоры).»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Айлык акчалата түләү Россия Федерациясе Президентының “Инвалид балаларны һәм балачактан I төркем инвалидларны тәрбияләүче затларга айлык түләүләр турында” 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы Указы белән билгеләнгән айлык түләүне алучы инвалид баланың законлы вәкиленә (ата-анасына, уллыкка алучыга, опекунга яисә попечительгә) (алга таба - мөрәҗәгать итүче) билгеләнә һәм түләнә.»;

7 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«исәп-хисап чорында мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Исемлекнең 3, 4 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән керемнәре булуын раслый торган документлар»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

8 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалид баланың законлы вәкиле Россия Федерациясе Президентының “Инвалид балаларны һәм балачактан I төркем инвалидларны тәрбияләүче затларга айлык түләүләр турында” 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы Указы белән билгеләнгән айлык түләүне алуы турында;»;

түбәндәге эчтәлекле 10[1] пункт өстәргә:

«10[1]. Ай саен акчалата түләү бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

инвалид баланың тулысынча дәүләт тәэминатында булуы;

гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре буенча бурычлары булу;

Татарстан Республикасында тиешле елга билгеләнгән бер кешегә исәпләнгән яшәү минимумы күләмен гаиләнең уртача исәпләнгән кеременнән арттыру;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык акчалата түләү алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактын ачыклау;

мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Президентының “Инвалид балаларны һәм балачактан I төркем инвалидларны тәрбияләүче затларга айлык түләүләр турында” 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы Указы белән билгеләнгән айлык түләүне алуы турында документларның (белешмәләрнең) булмавы.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Айлык акчалата түләү бирүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

инвалид баланың тулысынча дәүләт тәэминатында булуы;

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүе йә инвалид балага карата суд карары буенча аны ата-ана хокукларыннан чикләү;

инвалид баланың үлеме йә аны билгеләнгән тәртиптә үлгән яисә хәбәрсез югалган дип тану;

мөрәҗәгать итүчгә Россия Федерациясе Президентының “Инвалид балаларны һәм балачактан I төркем инвалидларны тәрбияләүче затларга айлык түләүләр

турында” 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы Указы белән билгеләнгән айлык түләү бирүне туктату»;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) инвалид баланың Татарстан Республикасыннан читтә даими яшәү урынына күченүе;

гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре буенча бурычлары булу.»;

121 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар 2026 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин